**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында**

Гражданнарны инициатива күрсәтүгә кызыксындыру һәм граждан җәмгыяте институтларын формалаштыруга ярдәм күрсәтү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен гамәлгә кую турында» 2015 елның 3 июлендәге ПУ-619 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 4 июнендәге ПУ-503 номерлы һәм 2017 елның 3 июнендәге ПУ-460 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе турындагы нигезләмәгә, 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә ел саен Премия түбәндәгечә тапшырыла:

һәрберсе 250 мең сум күләмендә өч Премия – гражданнарга (гражданнар төркемнәренә);

һәрберсе 400 мең сум күләмендә биш Премия – оешмаларга.».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы
Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 27 гыйнвар
№ ПУ-109